Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Трой-Урай авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 14**

Трой-Урай ав 2016 елның 8 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфалар биләүче затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү түләүне гамәлгә ашыру тәртибе турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру нормативлары турында "2007 елның 17 декабрендәге 722 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" 2007 елның 17 декабрендәге 722 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын, контроль-хисап органнары рәисләрен, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Трой-Урай авыл җирлеге”муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Билгеләү:

№ 1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хезмәт хакы күләме һәм шартлары;

2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә

чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибе.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр белән эшләгән өчен айлык өстәмә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, күләмнәрдә һәм тәртиптә түләнә дип билгеләргә.

4. Әлеге карар имза салынган көннән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. . Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Трой-Урай авылы, Мәктәп урамы, 13 нче йорт,Кама –буе урамы,9 йорт;Гремячка авылы, Александров урамы 24 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Трой-Урай авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафин